Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы
Ятмас-Дусай авылы җирлеге Советы

Карар

2019 елның 28 ноябре № 23

«Физик затлар мөлкәтенә салым турында»
2014 елның 24 ноябрендәге 33 номерлы
Ятмас-Дусай авылы җирлеге Советы
карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге нигезендә Ятмас-Дусай авылы җирлеге Советы карар бирде:

1. Ятмас-Дусай авылы җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 24 ноябрендәге 33 номерлы карарына (Ятмас-Дусай авыл җирлеге Советының 2015 елның 29 маендагы 24 номерлы, 2015 елның 13 октябрендәге 5 номерлы, 2018 елның 21 июнендәге 12 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктта:

а) 2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) фатирларга, фатир өлешләренә, бүлмәләргә карата – 0,2 процент»;

б) 3 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) түбәндәгеләргә карата 0,3 процент:

- торак йортлар, торак йортларның өлешләре;

- составына бер генә булса да торак йорт кергән Бердәм күчемсез комплекслар;

- төзелеп бетмәгән объектлар, әгәр мондый объектларның билгеләнеше торак йорт булса;»

1.2. алдагы эчтәлекле 3.1 пунктын өстәргә:

«3.1. Физик затларның мөлкәтенә салым түләүдән азат итәргә:

1) 18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк балалары булган гражданнарны;

2) әлеге пунктның 1 пунктчасында күрсәтелгән гражданнарның балаларын;»

Әлеге карарны Татарстан Республикасының Рәсми хокукый мәгълүмат порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча, шулай ук Ятмас-Дусай авылы җирлеге торак пунктлары территориясендә урнашкан махсус мәгълүмати стендларда урнаштырырга.

Әлеге карар 2020 елның 1 гыйнварыннан, әмма басылып чыккан көненнән соң кимендә бер ай узгач, үз көченә керә.

Ятмас-Дусай авыл җирлеге
башлыгы Ф.Х.Гарифуллина